Республика Татарстан
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КИЛЬДЕБЯКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
422071, Республика Татарстан,
с. Кильдебяк, ул. Кооперативная, 20а
тел. 45-5-50

Татарстан Республикасы
САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КИЛДЕБЭК АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
422071, Татарстан Республикасы,
Килдебәк авылы, Кооператив урамы, 20а йорт
тел. 45-5-50

Kilb.sab@tatar.ru

27.02.2019 №4

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен раслау хакында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131 — ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясы һәм Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Уставы нигезендә Килдебәк авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү буенча факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен расларга. (1 нче кушымта ).

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/kildebiak бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге башлыгы Н.Н. Заһидуллинга йөкләргә.

Килдебәк авыл җирлеге башлыгы: Н. Н. Заһидуллин

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге Башкарма комитетының 27.02.2019 №4 карарына кушымта №1

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәтләре өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару Тәртибе.

I. Гомуми нигезләмәләр.

1.1 «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Килдебәк авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү чыгымнарының факттагы күрсәткечләрен бастырып чыгару тәртибе (алга таба — Тәртип)

1.2. Тәртип Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләр тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели (алга таба — мәгълүматлар).

II. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында мәгълүмат тапшыру тәртибе һәм составы.

2.1. Мәгълүматлар квартал саен җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең уртача саны, шул исәптән хисап чорында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган Килдебәк авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны турында, шулай ук хисап чорында хезмәт хакына исәпләнгән түләүләрне (акчалата эчтәлек) исәпкә алмыйча, хезмәт өчен түләү чыгымнарын тормышка ашыруга юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләре күләмен чагылдыралар.

2.2. Мәгълүматлар хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосына кадәр әлеге Тәртипнең кушымтасы нигезендә бирелә.

2.3 Килдебәк авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма нигезендә мәгълүмат формалаштыра.

III. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибе.

3.1. Килдебәк авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан отчет чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча, мәгълүматларны раслау турында Килдебәк авыл җирлеге башкарма комитеты карар проекты әзерләнә.

3.1.Килдебәк авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган белешмәләр квартал саен хисап артыннан килүче икенче айның соңгы числосына кадәр Килдебәк авыл җирлеге сайтында бастырылырга тиеш.

Килдебәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәтләре өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибенә кушымта

____________20___ел хисап чорына (беренче квартал, ярты ел, тугыз ай, ел))
Килдебәк авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында мәгълүматлар

| Хезмәткәрләр категориясе | хисап чоры өчен, хезмәткәрләр саны | хисап чорына хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнар. (Мең сумнарда) |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Килдебәк авыл җирлеге муниципаль берәмлеге хезмәткәрләре | | |
| шул исәптән: муниципаль хезмәткәрләр | | |